**(Бишенче чакырыш)**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Кәкре Елга авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Кәкре Елга авылы № 13 «22» декабрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 нояберендәге 112 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (17.08.2015 № 137, 29.10.2015 № 12, 24.04.2018 № 91, 13.11.2018 №114, 28.12.2018 №121, 18.07.2019 №138, 05.11.2019 №139, 22.03.2021, 28.11.2024 №128-67 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында»2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Кәкре Елга авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 нояберендәге 112 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (17.08.2015 № 137, 29.10.2015 № 12, 24.04.2018 № 91, 13.11.2018 №114, 28.12.2018 №121, 18.07.2019 №138, 05.11.2019 №139, 22.03.2021, 28.11.2024 №128-67 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән объектлардан тыш, 2025-2027 елларга кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына 2 процент тәшкил итә»;

1.2. 2 пунктның 4.1 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo. tatarstan.ru

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә

һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.М.Мөхәмәтҗанов